**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет**

**Салманского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Салман авыл җирлеге Советы**

422874, РТ, Алькеевский район, с. Салманы, Молодежная 12

Тел.: 8 (84346) 72-2-38

Адресы: 422874, РТ, Әлки районы, Салман авылы, Яшләр ур., 12

Тел.: 8 (84346) 72-2-38

**РЕШЕНИЕ** **Салман** авылы **КАРАР**

2024 елның 16мае 81№

Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 ноябрендәге «Җир салымы турында» 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон , 2023 елның 31 июлендәге "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 ноябрендәге «Җир салымы турында» 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында ( яңа ред. 2022.11.04 27 №)карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяның 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"-0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән торак төзелеше (эшкуарлык

эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)".

2.Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге
Советы Рәисе И.В.Юсупов